ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 25 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында” 2016 елның 13 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2016, № 1 – 2), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“2. Әгәр салым түләүче – резидент социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территориядә эшчәнлек башкару турында килешүләрне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән ул резидентлар реестрына кертелгән салым чорыннан башлап рәттән килә торган өч салым чоры дәвамында (социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территориядә эшчәнлек башкару турындагы килешүдә капитал салулар күләме 500 миллион сумнан да ким булмаган күләмдә каралган очракта, рәттән килә торган биш салым чоры дәвамында; социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территориядә эшчәнлек башкару турындагы килешүдә капитал салулар күләме 1 миллиард сумнан да ким булмаган күләмдә каралган очракта, рәттән килә торган алты салым чоры дәвамында; социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территориядә эшчәнлек башкару турындагы килешүдә капитал салулар күләме 100 миллиард сумнан да ким булмаган күләмдә каралган очракта, рәттән килә торган тугыз салым чоры дәвамында) табыш алмаган булса, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган сроклар мондый салым түләүче резидентлар реестрына кертелгән салым чорыннан санала торган рәттән килгән дүртенче салым чорыннан (социаль-икътисадый үсеше

алдан билгеләнә торган территориядә эшчәнлек башкару турындагы килешүдә капитал салулар күләме 500 миллион сумнан да ким булмаган күләмдә каралган очракта, рәттән килгән алтынчы салым чорыннан; социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территориядә эшчәнлек башкару турындагы килешүдә капитал салулар күләме 1 миллиард сумнан да ким булмаган күләмдә каралган очракта, рәттән килгән җиденче салым чорыннан; социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территориядә эшчәнлек башкару турындагы килешүдә капитал салулар күләме 100 миллиард сумнан да ким булмаган күләмдә каралган очракта, рәттән килгән унынчы салым чорыннан) исәпләнә башлый.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2018 ел, 11 май
№ 26-ТРЗ